# КОЯШ ЧЫККАН, БАТКАН ЯКТА

*Рамазан Байтимеров* сүзләре






Сугыш уты кинәт каплап алды
Тыныч иртә, аяз ал таңны.
Ил уллары бердәм яуга китә,
Саклар өчен газиз Ватанны. } 2тапкыр

Күп батырлар илгә җиңеп кайтты,
Ә берәуләр ятып калдылар.
Кояш чыккан, баткан якка карап
Көтә–көтә күзләр талдылар. } 2 тапкыр

Җан кыелды азмы, кан коелды
Авыр көрәш барган якларда.
Бәлки, шуңа кояш кызарадыр
Чыккан чакта, баткан чакларда. } 2 тапкыр

Бәлки, шуңа кояш кызарадыр
Чыккан чакта, баткан чакларда.